КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 19 июль г.Казань № 597

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында мәктәп автобусларын нәтиҗәле файдалану чаралары турында» 2006 ел, 3 август, 400 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы белем алучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында мәктәп автобусларын нәтиҗәле файдалану чаралары турында» 2006 ел, 3 август, 400 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 29 ноябрь, 669 нчы; 2016 ел, 30 декабрь, 1070 нче; 2018 ел, 23 гыйнвар, 29 нчы; 2018 ел, 29 март, 192 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы белем алучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның икенче абзацында «2013 елның 17 декабрендәге 1177 номерлы» сүзләрен «2020 елның 23 сентябрендәге 1527 номерлы» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктта:

тугызынчы – унберенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«балалар төркемен оешкан төстә йөртә башлау датасына «D» категориясендәге транспорт чарасын йөртүче буларак эш стажы соңгы ике елның бер елыннан ким булган;

«Юл хәрәкәте иминлеге турында» Федераль законның 20 статьясындагы 2 пунктының икенче абзацы нигезендә Россия Федерациясе Транспорт министрлыгы тарафыннан расланган автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүләр иминлеген тәэмин итү кагыйдәләре нигезендә рейс алды инструктажы үткән;

балалар төркемен оешкан төстә йөртә башланганга кадәр бер ел эчендә юл хәрәкәте өлкәсендә административ хокук бозулар өчен транспорт чарасы белән идарә итү хокукыннан мәхрүм итү яки административ кулга алу рәвешендә административ җаваплылыкка тартылмаган.»;

уникенче абзац үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин